**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАРЫ

2020 елның 30 октябре № 1

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Ленино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы

карар кабул итте:

1. 2020 елның 14 ноябренә сәгать 14.00 да, Горшково авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында яшәүчеләр белән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Горшково авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Болын урамы, Заозерная урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, су анализы өчен түләү);

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү)

.

“РИЗА” «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылының мәгълүмат стендында урнаштырырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге Башлыгы М.Г. Дубровина